# Ислам нуры

«Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәтү бар»
(Коръән Кәрим. 2-256)

12+

№ 20 (696) 24 октябрь 2019 ел (1440, Сәфәр) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга


## Иң якын кешеләр

Дөньяда торган вакытта, шатлыкларны сөйләр, кайгыларны чишеп эчне бушатыр өчен иң якын, иң ышанычлы бер кешегә мохтаҗ булынадыр. Ләкин бу эшләр тугрысында ата белән анадан артык һичкем булмас, чөнки болар баланың шатлыгы өчен хәтта үзеннән артык сөенәдер вә хәсрәтләре өчен кулдан килгән барлык чараларны күрүдә кимчелек итмәсләр. Шуның өчен серләрегезне боларга сөйләгез, серләрегезнең хәзинәләре һәрвакытта



ата вә аналарыгызның күңелләрен булдырсын! Бәдәнегез үсеп көч кергәч тә, кулларыгыздан килгән эшләрдә ата вә аналарыгызга ярдәм итүче булыгыз, бәлки шәфкать вә хөрмәтләрегезне тагын да арттырыгыз, алар исә сезнең яшь вакытларыгызда вә иң зәгыйфь булган көнегездә тәрбияләп сезне үстергәннәр. Бер көн җитәр, сез дә ата булырсыз, исәпләп карагыз, шул көндә балаларыгыз хөрмәтегезне сакламасалар, риза була белерсезме? Иң изге Рәсүл (Аңа Аллаһы Тәгаләнең хәер догасы һәм сәламе булсын) әфәндебез хәзрәтләренең: “Аталарыгызга изгелек итегез, сезгә балаларыгыз изгелек итәр”, – дигән мәгънәдә бер сүзе бар.

**(Риза Фәхреддин. «Әхлак гыйлеме»ннән.)**

## Чаллы яңалыклары



10 октябрь көнне “Ак мәчет” мәдрәсәсендә Чаллы һәм күрше шәһәр мәчетләрендә якшәмбе дәресләрен алып баручы укытучылар өчен конференция булды. Әлеге чара “Ак мәчет” мәдрәсәсе Рөстәм хәзрәт Шәйхевәлиев һәм Чаллы шәһәре имам-мөхтәсибе урынбасары Фоат хәзрәт Мөхәммәтовның мөгаллимнәрне сәламлау сүзләре белән башланды. “Чаллы Яр” мәхәлләсе имам-хатыйбы Илдар хәзрәт Зияров мәчет мөгаллимнәрен Татарстан мөселман уку йортлары мөгаллимнәре форумында алынган мәгълүмат белән таныштырды. Үзенең чыгышында ул укырга килгән кешеләргә безнең республикада кабул ителгән Әбү Хәнифә мәзхәбе нигезендә ТР МДН тарафыннан хупланган белемне генә бирергә һәм мөселманнар арасында фетнә чыгаручы чит ил галимнәре идеологиясенә кагылмаска чакырды. Чит идеологиянең безнең милләт, дәүләт таркалуына сәбәп булуын ассызыклады. Шулай ук мөселманнар арасында дини генә түгел, дөньяви белемле кешеләрнең дә кирәклеген ассызыклады.

Чара азагында Коръән укып дога кылынды.

***

20 октябрь көнне Алабуга районының Хлыстово авылында урнашкан спорт үзәгендә V рәсәйкүләм спорт ярышлары узды. Бәйгедә республиканың 14 районыннан һәм Башкортстаннан килгән мөселман яшьләре мини-футбол, кул көрәше, аркан тартышу, гер күтәрү һәм турникта күтәрелү кебек ярышларда көч сынашты. Биредә Чаллы шәһәреннән дә спортчылар бар иде. Алар арасыннан “Утыз Имәни” мәчете командасы спортчысы Илдар Хаматов гер күтәрү буенча 3 урынны, “Нур-Ихлас” мәчетенә йөрүче Фәнис Нурмөхәммәтов кул көрәшендә 3 урынны, ә



аркан тартышу ярышында Казан-Чаллы берләшкән командасы беренче урынны яулады.

***

Игътибар!

Мәүлид аена багышлап, “Минем Пәйгамбәрем” дип аталган темага видео-роликлар буенча конкурс уздырыла. Уздыру вакыты: 12 октябрьдән 12 ноябрьгә чаклы.Катнашучыларга таләпләр: Мөселман булу. Яшь арасы чикләнмәгән. Видео-материалга таләпләр: Татар телендә булу һәм эчтәлегенең темага туры килүе. Вакыты 5 минуттан артмаска тиеш. Җиңүчеләрне сайлау: 13-15 ноябрь. Сайлау вакытында беренче урында видео-роликның эчтәлеге торачак. Осталык һәм видео сыйфаты – икенче урында. Бүләкләү: Шәһәркүләм Мәүлид кичәсе. Призлар: 1 урын – 5000 сум, 2 урын – 3000 сум, 3 урын – 2000 сум. Конкурста җиңүчеләрнең видео-роликлары шәһәркүләм Мәүлид кичәсе программасында халыкка күрсәтеләчәк. Бәйгедә катнашу өчен әзер видео-материалларны muhtasibchelny@yandex.ru почтасына җибәрү сорала. Шулай ук конкурста видеоязманы Instagram социаль челтәренә салып, @islamchally аккаунтын видео астына беркетеп тә катнашып була.

**Нияз ГАЗИЗОВ.**

## ТР МДН хәбәр итә

Сәфәр аеның 18 нче көнендә, Мәскәүдә бөтен татар дөньясы өчен зур тарихи вакыйга узды – Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге Тулы вәкаләтле вәкиллеге мәйданчыгында ТР мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан әзерләнгән «Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә» басмасы – Коръәннең татар теленә тәрҗемәсе тәкъдим ителде. Чарада мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин, ТР Премьер-министры урынбасары – ТРның Россия Федерациясендә тулы вәкаләтле вәкиле Равил Әхмәтшин, ТР мөфтиенең беренче урынбасары Рөстәм хәзрәт Вәлиуллин, ТРның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, мөфтинең мәгълүмати сәясәт буенча киңәшчесе һәм “Хозур” нәшрият йорты директоры Ришат Хәмидуллин һәм ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Шәригать мәсьәләләре буенча бүлек җитәкчесе Булат хәзрәт Мөбарәков катнашты.

***

Сәфәр аеның 16 нчы көнендә, Татарстанның 16 шәһәрендә һәм районында татар телен өйрәнү буенча мәчет каршындагы курслар рәсми рәвештә башланып китте. Республика мәчетләрендә татар теле курсларына йөрергә теләүчеләрнең саны 300 кешедән артып китте. Быел татар теле курслары 20 мәйданчыкта, шул исәптән республиканың 15 мөхтәсибәтендә – Әгерже, Әлмәт, Бөгелмә, Буа, Югары Ослан, Алабуга, Яшел Үзән, Лениногорск, Лаеш, Менделеевск, Яр Чаллы, Түбән Кама, Норлат, Чистай, Ютазы мөхтәсибәтләрендә үткәреләчәк. Башкалада курсларны «Ризван», «Тынычлык», «Казан нуры», «Гаилә» мәчетләрендә, шулай ук Россия ислам институтында тыңларга мөмкин.

***

Казанда үсешләрендә үзенчәлекләре булган балалар, яшүсмерләр, яшьләрне кыска вакытка калдыру үзәге эшли башлады. Социаль проект ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды тарафыннан тормышка ашырыла. Проект нигезендә махсус эшләнгән укыту программасы ята, ул түбәндәге бүлекләрне үз эченә ала: социаль-мәдәни һәм иҗади адаптация курслары программалары; физик тернәкләндерү һәм дәвалау физкультурасы курсларын үстерү программалары; психоэмоциональ ярдәм курслары программалары; мәдәни-ял итү программасы.

Дәресләр һәр укучыга мөмкин кадәр уңайлы булырлык итеп төзелгән, аларның эчтәлеге интеллект дәрәҗәсенә, курсларда катнашучыларның физик һәм психологик торышына карап үзгәрә.

## ЯҢА КИТАП




Чаллының «Ислам нуры» нәшриятында Кукмара мәдрәсәсе мөдире Ришат хәзрәт Курамшинның “Күңел күзе” дип аталган китабының икенче, яңартылган басмасы дөнья күрде. Өч өлештән торган китапның эчтәлеге яңа хикәя-шигырьләр, шулай ук галимнәрнең хикмәтле гыйбарәләре белән тулыландырылды. Бу китапта һәркем гыйбрәт алырлык, күңелне яктыртырлык, иманны ныгытырлык мәгълүмат таба ала.

# Бар нәрсә Аллаһтан

*Кадерле дин кардәшләрем!*

*Без Коръәндә искә алынган пәйгамбәрләр турында байтак вәгазьләр тәкъдим иттек. Бүген исә диңгез төбенә төшкән, бик авыр вакытта Аллаһы Тәгаләдән бер хикмәтле чишелеш килгән, беркем дә сәҗдә кылмаган җирдә сәҗдә кылган пәйгамбәр турында, Йуныс (галәйһиссәләм) турында белербез.*

Йуныс пәйгамбәр - Биниәминнең (Ягъкуб галәйһиссәләмнең улы, ягъни Йосыф галәйһиссәләмнең энесе Биниәминнең) оныгы иде. Аллаһы Тәгалә аны Мусылә җирләренә, хәзерге Ирак территориясе, Нәйнәүә шәһәрендә яшәүче, потларга табынучы кавемгә пәйгамбәр итеп җибәрә. Хәзрәти Йуныс (галәйһиссәләм) бу кавемне гаять зур сабырлык белән хак дингә, бер Аллаһка гыйбадәт кылырга өнди. Кызганычка каршы, күпме генә вәгазьләсә дә, бу кавемнең халкы аңа колак салмый, алар Йуныс (галәйһиссәләм) чакырган хак динне кабул итмиләр. Шуннан Йуныс (галәйһиссәләм):" Әгәр иман китермәсәгез, өч көн эчендә өстегезгә Аллаһтан газап киләчәк",- дип, бу кавемне ташлап чыгып китә.

Аллаһы Тәгалә бу турыда болай ди: "Ачуланып кавеменнән аерылып китте, ул уйлады кавемен ташлап киткән өчен Безнең аңа хөкем булмас дип". Йуныс (галәйһиссәләм) үз кавеменә хак динне кабул итмәгәннәре өчен бик ачулана һәм аларны Аллаһы Тәгалә хөкеменә калдырып, чыгып китә. Бу халык башта ышанмый. Өч көн булгач, күктә утлар күренә башлый. Шул вакыт куркып, Йунысны эзләргә тотыналар, ләкин тапмыйлар. Инде бу кавем аңга килә, бик нык хаталанганнарын аңлап ала. Йуныс (галәйһиссәләм)нең пәйгамбәр икәненә ышаналар, бу халыкның һәммәсе, иман китереп, тәүбә итәләр. Аллаһы Тәгалә Үзенең хикмәте белән тәүбәгә килүне аларның йөрәкләренә, күңелләренә сала. Алар Йуныс (галәйһиссәләм)гә гаделсезлек күрсәткәннәре өчен бик үкенәләр. Ибн Кәсир әйтә: "Барча халык, хәтта кечкенә бәбиләре булган аналар да, сабыйларын күтәреп, бар булган терлек-хайваннарын куалап, ачык урынга чыгалар һәм төркем-төркем булып бүленәләр. Шулхәтле бирелеп тәүбә итәләр, тәүбәдән башка бернәрсә аларны борчымый, хәтта кычкырып-кычкырып елаган балаларының да тавышларына игътибар итмиләр. Барчасы: ирләр дә, хатыннар да, балалар да, хәтта хайваннарга кадәр Аллаһы Тәгаләгә иман китереп, елый-елый, Аллаһы Тәгаләдән кичерүен үтенергә тотыналар. Йөз мең кеше чамасы булалар. Күз алдына гына китереп карагыз әле, йөз мең кеше күзләреннән яшь агызып, тәүбәгә килеп, Аллаһы Тәгаләдән кичерүен сорый, Йуныс (галәйһиссәләм)не тыңламаганнары өчен бик үкенәләр инде алар. Ибн Кәсир моның турында: "Бу бик зур вакыйга була",- ди.

Һәм Аллаһы Тәгалә аларны гафу итә. Аллаһы Тәгаләнең җәзасы бик якын була, әмма Ул аларны Үзенең җәзасыннан коткара. Аллаһы Тәгалә бу турыда болай ди: "Йуныс кавеменнән башка, һичбер кавемнең газапны күргәч кенә китергән иманнары файда бирмәде. Чөнки Йуныс кавеме иман китергәч, алардан дөнья газабын бетердек вә әҗәлләре җиткәнче файдаландырдык".

Игътибар итегез, Йуныс (галәйһиссәләм) үз халкын иманга килмәс дип саный, хәтта аларга Аллаһы Тәгаләнең җәзасы киләчәк вакытны да билгеләп куя. Әмма Аллаһы Тәгалә аларның иманга килүен теләи.

Шуңа күрә, йә кардәшем, аңларга кирәк: бу дөньяда бар нәрсә Аллаһтан. Кешенең иманга килүе дә, килмәве дә бер Аллаһтан. Карагыз, Йуныс пәйгамбәр дә кавеменең кайчан да булса иманга килүенә өметен өзгән, әмма Аллаһы Тәгалә бу кавемне иманга китергән. Бәлки әле сезнең арада да гаиләләре, ирләре, хатыннары я башка туганнары яисә якыннары иманга килмәгән кешеләр бардыр. Өметегезне өзмәгез, Аллаһы Тәгаләнең кодрәте киң.

Йуныс пәйгамбәр, башка җирләргә чыгып китү өчен, көймәгә утыра. Аллаһы Тәгалә бу турыда болай ди: «Һәм Йуныс та Безнең җибәргән пәйгамбәрләребездәндер».

Йуныс, иман китермәгән кавемен ташлап, кешеләр белән тулган зур көймәгә керде. Диңгез буйлап барганда бик нык шторм күтәрелә. Көймә бату куркынычы туа. Шуннан көймәдәге бар авыр әйберне диңгезгә ташлыйлар. Бу да ярдәм итми. Көймәдәге кешеләр саны күп була, бу хәтле кешене көймә күтәрә алмый. Инде кешеләрнең кайберсенә, көймә батмасын өчен, ачык диңгезгә сикерергә туры килә. Шобага салалар. Шобага беренче тапкыр Йуныс (галәйһиссәләм)гә чыга, шуннан тагын бер тапкыр шобага салалар, тагын Йуныска (галәйһиссәләм)гә чыга. Шуннан тагын бер тапкыр шобага салырга булалар, ул өченчесендә дә Йуныска (галәйһиссәләм)гә чыга. Аллаһы Тәгалә бу турыда Коръәндә: «Ул башкалар белән бергә шобага сала, әмма оттыра», - ди.

Беренче карашка инде үлеме килеп җиткән кебек. Әмма без еш ялгышабыз. Йуныс (галәйһиссәләм) не көймәдән диңгезгә ташлаган вакытта яннарыннан бер кит узып бара һәм Аллаһы Тәгалә аңа Йуныс (галәйһиссәләм)не йотарга боера.

Аллаһы Тәгалә әйтә: «Ул шелтәгә лаек вакытта аны балык йотты».

Ибн Кәсир әйтә: "Аллаһы Тәгалә китка, Йуныска зыян килмәслек итеп, аны йотарга боера. Ул синең ризыгың түгел, итенә, сөягенә зыян китермә!"- ди ул китка.

Йуныс (галәйһиссәләм) кит эчендә: "Инде үлдем",- дип уйлый. Аннан аякларын селкетеп карый, аяклары исән-сау, шуннан ул кит эчендә һәм үзенең исән икәнен аңлап ала. Шунда ук торып, Аллаһы Тәгаләгә сәҗдә кыла: «Йә Раббым, мин сиңа моңарчы беркем гыйбадәт кылмаган җирдә сәҗдә кылам», - ди.

Күпме вакыт үткәрә соң ул анда? Берәүләр өч көн ди, икенчеләр җиде көн, өченчеләр кырык көн чамасы, диләр.

Кит эчендә дөм караңгы була. Аллаһы Тәгалә әйтә: «Ул караңгылыктан мөрәҗәгать итте».

Йуныс өч кат караңгылык эчендә була. Беренчесе - кит эчендәге караңгылык, икенчесе - диңгез төбендәге караңгылык, өченчесе - төн караңгылыгы.

Үзегезне Йуныс (галәйһиссәләм) урынында итеп күз алдына китереп карагыз әле. Ул кит эчендә. Анда шулхәтле караңгы, хәтта үзеңнең кул-аягыңны да күреп булмый, һәрвакыт юеш. Бу коточкыч зур кит аны теләсә кайчан ашап бетерергә мөмкин. Ничек куркыныч!

Ибн Кәсир әйтә: "Кит эчендә диңгез буйлап йөзгәндә Йуныс (галәйһиссәләм) башка китларның Аллаһка зекер итүләрен, аннан да бигрәк, хәтта диңгез төбендәге ташларның да Аллаһка зекер итүләрен ишетә. Шунда Йуныс (галәйһиссәләм) Аллаһка: «Йә Аллаһ, Синнән башка һич иләһ юк, мәгәр Син генә, Сине һәр кимчелектән пакъ дип беләмен. Синең рөхсәтеңнән башка кавемемне ташлап китүем белән үземә золым итүчеләрдән булдым!» - ди.

СөбеханәАллаһ, менә бу дога! Уйланыгыз әле, Аллаһы Тәгаләне ничек югары күтәрә ул, үзенең нинди түбән хәлдә икәнен аңлый, хаталарын таный. Ул шулхәтле курка Аллаһы Тәгаләдән, хәтта кичерүен турыдан-туры сорарга ояла. Йә Аллаһ, мине кичер, коткар, дими ул. Юк! Аллаһы Тәгаләне мактый! Зекерләрнең иң яхшысын, «ләә иләәһә илләә Аллаһ» тәүхид кәлимәсен әйтә, гөнаһ кылганына бик үкенә, тәүбә итә. Үз кавеменең кылганнарына түзә алмаганга, өметен өзгәнгә үкенә. Сабырлык белән үз кавеменең иманга килгәнен көтә алмаганга, Аллаһы Тәгаләдән шушы сынау килүен аңлый ул.

Аллаһы Тәгалә аның догасын кабул итә: «Без аның догасын кабул иттек һәм аны кайгы-хәсрәттән имин кылдык. Без иман ияләрен шулай коткарачакбыз». Шулай ук Аллаһ Тәгалә әйтә: «Әгәр ул тәсбих кылучылардан булмаган булса, Без аны кит корсагында Кыямәт көненә кадәр калдырыр идек».

Ягъни, бер Аллаһка табынганга, йөрәгендә бер Аллаһ булганга, Аллаһы Тәгалә аны коткара. Аллаһы Тәгалә: "Әгәр ул зекер итмәгән булса, Кыямәт көненә кадәр кит эчендә булыр иде", - ди.

Ибн Җарир Тәбәри үзенең тәфсирендә болай ди: "Кит Йунысны йоткач, ул кит эчендә диңгез төбенә төшә. Анда ул бер тавыш ишетә, шуннан аптырап кала, нинди тавыш булырга мөмкин диңгез төбендә? Аллаһы Тәгалә аңа бу тавышның диңгездәге хайваннарның тәсбихе икәнен төшендерә. Шуннан Йуныс (галәйһиссәләм) кит эчендә сөбеханәАллаһ дип тәсбих әйтә башлый. Фәрештәләр бу тәсбихне ишетеп: "Йә Аллаһ! Без бер дә ишетмәгән, гаҗәеп бер җирдән тавыш ишетәбез", - диләр. Аллаһы Тәгалә аларга: "Бу минем колым Йуныс, ул Мине тыңламады һәм Мин аны кит эченә бикләп куйдым", - ди. Фәрештәләр Аллаһка: " Ул моңынчы көн дә, төн дә бер Сиңа гыйбадәт кылган хак колың бит", - дип Аллаһтан аны коткаруын үтенергә тотыналар. Шуннан Аллаһы Тәгалә китка Йунысны яр буенда калдырырга куша.

СөбеханәАллах! Бу Пәйгамбәребез бертуганының улына үгет-нәсихәт кылганда дәлилләнә: "Аллаһны сакла һәм Аллаһ та сине саклар, Аллаһны сакла һәм син Аны үз алдыңда итеп табарсың. Сиңа рәхәт чакта, Син имин чакта Аллаһны таны һәм Аллаһ сине авыр чакта таныр".

Башка тәфсирдә Аллаһы Тәгалә Йуныс (галәйһиссәләм)не ул моңарчы Аллаһка гыйбадәт кылганы өчен коткарды диелә.

Шуңа күрә, кардәшем, яхшы эшләр эшләргә кирәклегенә җиңел карама. Бәлки, син биргән сәдака, яки тоткан уразаң, кешеләргә яхшы мөгамәләдә булуың сине иң кирәк вакытта коткарыр.

Шуннан Аллаһы Тәгалә китка Йуныс (галәйһиссәләм) не яр буенда калдырырга әмер бирә. Аллаһы Тәгалә бу турыда: «Без аны ачык урында ташладык һәм ул бик авырый башлый», - ди.

Балык эчендә байтак вакыт булган тәнне күз алдыгызга китереп карагыз әле. Ул көчсезләнә, зәгыйфькә әйләнә, авырый. Бераз вакыт су эчендә утырсак та, тәнебезнең тиресе үзгәрә, бозыла башлый бит. Әмма Аллаһы Тәгалә аны бу авыр чакта калдырмый, аны кайгырта, тәнен сихәтләндерә.

Аллаһы Тәгалә әйтә: «Без аның өстеннән яки аның янында кабак үстердек», - ди.

Һәм Йуныс янында кабак агачы үсеп чыга, аны эссе кояштан һәм бөҗәкләрдән саклый. Аллаһ Тәгалә үзенең бәрәкәте белән аның тәнен тулысынча сихәтләндерә.

Шуның белән генә Аллаһы Тәгаләнең шәфкате бетәме соң? Юк, җәмәгать! Аллаһы Тәгаләнең бүләкләве турында сүз барганда, без аның күләмен күз алдына да китерә алмыйбыз. Бик күп, кадерле, кыйммәтле бүләкләү ул. Аллаһы Тәгалә Йуныс(галәйһиссәләм)не үз кавемендәге барча кешеләрнең тәүбәгә килүе белән куандыра.

Аллаһы Тәгалә бу турыда: «Без аны йөз меңгә, яки аннан да күбрәкләргә җибәрдек. Алар иман китерделәр һәм Без аларга билгеле бер вакытка кадәр нигъмәтләрдән файдаланырга рөхсәт иттек», - ди.

Карагыз, ничек юмарт Аллаһы Тәгалә! Аллаһы Тәгалә Йунысны диңгездәге үлемнән, кит эчендәге авырлыклардан коткарып кына калмый, ә тәнен сихәтләндерә, хәтта кавемендәге бар халкының иманга килүе белән аны куандыра. Бу барыбызга да нәсихәт, дин кардәшләрем! Беркайчан да кешеләрнең иман китерүеннән өметеңне җуйма. Нихәтле генә кеше түбән тәгәрәмәсен, нихәтле гөнаһка чуммасын, читкә борылма. Аллаһы Тәгаләдән авыр вакытта ярдәм көтәбез икән, рәхәт, яхшы чакта да, көчең булганда да гыйбадәт кыл.

Йә кардәшем! Әгәр син Аллаһтан нигъмәт көтәсең икән, исеңә төшер, үзең соң син соңгы тапкыр мохтаҗларга кайчан булыштың?...

Син Аллаһы Тәгаләдән авыр чакта ярдәм сорыйсың, ә үзең соң кайчан ярдәм иттең? Хәтта кемгәдер машинасын кабызырга булышу да, кемгәдер авыр сумкасын күтәрешеп бару да ярдәм бит?!

Игътибар итегез: Коръәндә диңгездә батучы ике кеше турында телгә алына. Аларның берсе Аллаһы Тәгаләнең дошманы, ә икенчесе Аллаһы Тәгаләнең Пәйгамбәре. Аларның икесе дә Аллаһы Тәгаләгә дога кыла. Икесенең дә догасы күкләргә күтәрелә. Аллаһның дошманының догасы кабул булмый, һәм ул һәлак була, түбәнсетелә. Ә Пәйгамбәрнең догасы кабул була. Догасы кабул булган Пәйгамбәр ул - Йуныс, ә Аллаһның дошманы - Фиргәвен.

**Әбүбәкер хәзрәт ӘБДИЕВ, Чаллының "Тәүбә" мәчете имам-хатыйбы.**

# МӘҮЛИД КИЧӘСЕ

Рабигыль-әүвәл аеның унбереннән уникесенә каршы төнендә Аллаһы Тәгалә бар галәмнәргә рәхмәт буларак кешелекнең өстенлеген һәм мактаулы сыйфатларын үзенә туплаган соңгы Пәйгамбәрен дөньяга бирә. “Мәүлид” сүзе “туу вакыты” яисә “туган көн” дигән мәгънәне белдерә. Ислам дөньясында бу көнгә мәүлиддин-Нәби, ягъни Мөхәммәд пәйгамбәрнең туган көне диләр. Ул мөселман һиҗри айлары буенча, рабигыль-әүвәл аеның 11нче кичен 12 нче көненә бәйләгән төн уртасыннан соң Мәккә шәһәрендә туа. Нәкъ 63 ел яши һәм шул ук айның шул ук көнендә вафат була, ягъни туган һәм үлгән көннәре бер үк көннәргә туры килә. Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в. 571 елда туган. Атасы Габдулла, улы тумастан ике ай әүвәл вафат булса, анасы Әминә баласына 6 яшь вакытта вафат була. Мөхәммәд сигез яшенә кадәр бабасы Габделмотталлиб, 25 яшенә кадәр абзыйсы Әбү Талиб карамагында яши. 25 яшенә җиткәч, Хәдичәгә өйләнә. Бу никахтан 2 ул һәм 4 кыз туа. 40 яшенә җиткәч, пәйгамбәр була, бу шәрәфле вазыйфаны 23 ел дәвамында үтәп килә. Пәйгамбәребез с.г.в. 63 яшендә Мәдинә шәһәрендә вафат була. Пәйгамбәр Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең туган көне гасырлар дәвамында дөньяның төрле почмакларында билгеләп үтелә. Шулай ук Мәүлид ән-Нәби – татар халкының иң борынгы һәм тирән хөрмәткә ия бәйрәмнәренең берсе. Бу көнне безнең бабаларыбыз бергә җыелганнар, дога укыганнар, салаватлар, мөнәҗәтләр һәм касыйдәләр әйткәннәр. Моннан тыш, алар Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне искә төшергәннәр, аның образын, тормыш юлын һәм мирасын хәтердә яңартканнар. Бүген дә Мәүлид мәҗлесләре Пәйгамбәребез узган юлны һәм аның сөннәт гамәлләрен бер-беребезгә искә төшерүне, аның күркәм әхлакый үрнәген өлге итеп алуны, рухыбызны тәрбияләү һәм ныгытуны максат итеп куя.

**ӘДӘБИ СҮЗ**

## Шөкер итеп яшик

*Иртән торсам, ихлас күңелемнән*
*Дога кылам, сөенеп, Ходайга.*
*Мең-мең рәхмәт, Аллам, бүген дә мин*
*Аягымда басып торганга.*
*Хәерләре белән килсен, Раббым -*
*Картлыгым да килеп җитте бит.*
*Шатланамын, сөенәмен генә -*
*Аягымда йөреп торам бит.*
*Балачак белән яшьлек*
*Бик тиз үткән икән бит.*
*Кай арада картлыгы да*
*Килеп җиткән икән бит...*
*Картлык бит ул шундый нәрсә -*
*Бик тиз килә дә җитә.*
*Ә кемнәрдер шул картлыкны*
*Күрми дә үлеп китә...*
*Еллар кырыс, мәрхәмәтсез,*
*Маңгайга сырлар сала.*
*Шулай дөнья куа-куа,*
*Гомерләр дә кыскара.*
*Узса узсын әйдә бу гомерләр,*
*Бирешмик без әле юк-барга.*
*Шатланышып, шөкер итеп яшик*
*Аллаһ биргән нигъмәт-саулыкка.*
*Бер-беребез белән аралашып,*
*Күрешеп яшик фани дөньяда.*
*Бәхет бит ул сезне күреп яшәү -*
*Авылдашлар исән булганда.*
*Җыелышып бер утырыйк әле,*
*Бер утыру - үзе бер гомер.*
*Исән чакның кадерләрен белик,*
*Үткәннәрне искә төшерик...*

***Рәҗимә ВАХИТОВА,***
***Актаныш районы Качкын авылы.***

*Юл язмасы*

# “Әти димәде, бер кеше, диде...”

***Зөләйха ханымны әкрен генә атлаган җиреннән йорт каршысында очраттым. Уклау йоткандай төз гәүдәле, кайчан күрмә, гел биек үкчәле түфли кияргә яратучы бу ханым табиб булып эшли, гаҗәеп ачык йөзле, якты карашлы; төс-кыяфәтенә карасаң, аның бер кайгысы да юк кебек күренә...***

- Элекке иремне җирләдек, шуның бүлмәсен юып кайтып киләм. Ярый әле балаларым булды, бөтен мәшәкатьләрне алар ерып чыкты. Җир җимертеп йөргән чагында, без беребез дә кирәкми идек тә, теге дөньяга киткән чагында булса да кирәгебез чыкты тагын... Әй, сөйләсәң, гыйбрәт инде ул... Ильяс белән студент чагында танышкан идек. Икебез дә медицина институтында укыдык без. Бик чибәр егет иде: ул озын буй, янып торган зәп-зәңгәр күзләр дисеңме. Мин үзем дә ул вакытта карап кына тормалы идем шул, чәчләр көдрә, бил нечкә... Кызлар үзләре кызыга иде Ильяска, муенына гына килеп сарылмыйлар иде инде. Алай дисәң, андыйлары да булгандыр. Яшьлек сукырлыгы белән мин генә күрмәгәнмедер... Укуны бетергәч, икебезне дә бер шәһәргә эшкә билгеләделәр. Болай да өйләнешәбез дип сөйләшкән идек инде, гаиләлеләргә фатир була икән дигәч, туйны тизләттек, әти-әниләрне шәһәргә генә чакырып, язылышып та куйдык. Аныкылар ныклы нәсел, күкрәп торалар, минем әткәй институтка кергән елымда вафат булды. Шул: туйдан соң өч айлап икебез ике тулай торакта яшәдек әле, аннан соң озак тотмадылар, чыннан да фатир биреп куйдылар. Бәхетле еллар диген. Сөенә-сөенә шунда икәүләп әйбер җыйдык, кулдан килгәнчә бүлмәләрне киендердек, ике улыбыз туды. Алар дөбердәп үсеп килгәндә, өченчесен дә алып кайттым. Кыз, кыз кирәк дип йөргән идек, сәламәт бала булсын дип теләргә оныттык микән – гарип, авыру булып туды кызыбыз. Үзебез врач булгач, андый диагнозның ни икәнен бик әйбәт аңлый идек. Роддомдагы врачлар да: “Калдырып чыксагыз, үзегез өчен җиңелрәк булыр”, – дип кат-кат үгетләделәр. Авыру булса да, үз жаныңнан өзелеп төшкән сабый бит ул, ничекләр калдырасың... И-и, ул чакта кичергәннәр... Яшерен-батырын түгел, үлсә-үлә, калса-кала дип уйлаган чакларыбыз да булгалады. Гаҗәп инде, андыйлар тагын да чырышрак була микән – тормышка чытырдап ябышкан иде сабый. Төн йокылары күрмичә үстерә-үстерә, бала өч яшькә җиткәч, Ильясның холкы җен алыштырган сыман була башлады. Баланың акыл зәгыйфь, ни кыланганын белми, әтиебез алҗап кайтты ни аңа, төнге сменадан кайтып ауды ни... Өйдә талаш-ызгыш китте, Ильяс мине гаепләргә тотынды: “Врачлар калдыр дигәндә калдырып кына чыгасы иде, син беренче дә түгел, соңгы да булмас идең”, – дип үзәгемне өзде. Малайлар үсеп киләләр иде, аталары холыксызланган вакытта үз бүлмәләрендә шым гына утыралар. Кечесе шул мәлләрдә куркыбрак калды да инде, тотлыга да башлады сабыем... Кызыбызга яшь өстәлгән саен үзем күрер күзгә картая идем. Кешегә йөрү, өйгә кунак чакыру бетте, ирем өйдә булса, кара тавыш. Бөтен нәрсә аның ачуын китерә иде: телевизорның тавышы катырак ачылса да, кысыбрак куелса да, ак ипи урынына кара ипи кайтса да, карасы урынына ак куелса да. Аш пешерәсең – аның ботка ашыйсы килгән икән, ботка әзерлисең – нигә аш пешерергә ирендең... “Чирле бала карап, үзең авыруга әйләндең бит инде, көзгегә кара, кемгә охшагансың”, – дип йөземә бәреп әйткән чаклары ешайганнан ешайды. Аны-моны уйлау башыма да килгәне юк иде, бер медсестра кыз күземне ачты: “Ильяс абый әллә хәзер сезнең белән яшәмиме ул? Нина Петровна фатирына күчкән, диләр бит”, – дип, ушымны алды. Нина Петровна дигәне – ирем эшләгән больницада терапевт, сап-сары чәчле, курчак кебек яшь хатын, ире белән икеме-өчме ел элек аерылышкан иде. Иремнең атнасына җиде тапкырга әверелгән төнге сменалары “эшләргә кеше булмау” сәбәпле түгел, димәк... Медсестраның әйткәне хак булып чыкты. Өйдә җәнҗал куптарырга Ильяс үзе әзерләнеп кайтты: бу фатирда аңа бернинди кызык юк икән, ул бөтен гомерен гарип бала тәрбияләп үткәрергә җыенмый, башкага өйләнсә, аңа бер түгел, ун сәламәт бала алып кайтачак... Бу сүзләрне ишеткәч, минем истерикам башланды; ул чагында безнең фатирда яу үткән кебек булгандыр, мөгаен. Акыра-акыра елаганымны хәтерлим әле, “ул бала минеке генә мени, синең бер өлешең дә юкмыныи”, дия-дия, идәндә шуыша-шуыша еладым. Гарип баладан башка, сау-сәламәт ике малай да бар бит әле! Тере аталары була торып, алар ятим үссенме? Ильясның күзе-башы томаланган иде, безнең күз яшьләре генә тотып кала алмады аны, шул хатын янына чыгып китте.

Үз тормышым турында җәелеп сөйлисем килми. Телемне аркылы тешләп булса да, малайларымны үстердем, кеше иттем. Кызым унөч яшендә үлде, кеше, “котылдың”, дип мине юатырга маташканда, мин җир тырмап-тырмап еладым. Кызым иде бит ул минем, карынымнан өзелгән балам иде! Ярар, аның урыны оҗмахның түрендәдер... Ильяс баштарак малайларга бүләкләр алып бирә, бераз акча калдыра торган иде, тегендә уртак балалары тугач, безнең янга сукмак онытылды. Олысы өйләнгәндә, әдәп йөзеннән булса да дип, туйга чакырдык, әй өметләнгән иде улыкаем, әтисе ЗАГСка булса да килер, котлау сүзе әйтер ди. Тегесе, чакыра баргач, килердәй ышандырып калган булган. Килмәде, күренмәде, котлау сүзе әйтеп, телефоннан шалтыратса да гарьләнмәс идек... Шул чагында улымның эчендә нинди ялкыннар булды икән дим...

Берничә ел элек Ильясның бер аягын бот төбеннән кистеләр. Күрәчәгең булса, күркә талап үтерер диләр бит... Аның аягы пешкән булган, бер бармагы пешеп-кызарып йөргән дә зурга киткән. Белмим инде, үзе врач була торып, нишләп бер дә уйламагандыр... Ильяста шикәр чире булган, аягында гангрена башлана дип, башта тез астыннан, аннан бот төбеннән үк кисеп атканнар.... Дөрес фаразлыйсың, маржа хатыны гарип ирне кирәксенмәде... Ильясны бер бүлмәле фатирга куып дигәндәй чыгаргач, аны ашатырга, юындырырга кече улым белән без йөрдек. Ни өченме? Белмим. Үзем дә белмим. Күңелемдә аңа карата берни дә юк иде, мәхәббәт турында әйтәсе дә юк инде, анысы әллә кайчан көл булган. Кызганумы, үзем врач булгач, авыру кешегә булышу теләгеме? Югыйсә, ул кешенең кайчандыр газиз ирем булганлыгы әллә кайчан онытылган кебек иде. Онытылмый икән ул, сеңлем, яралы җаныңның бер почмагында сыкрап булса да яшәп ята икән... Теге малае да килгәләп йөрде. Нина гына: “Аягың бар чагында бер кочактан икенче кочакка йөрдең, теләсә нишлә”, – дип бөтенләй кул селтәгән иде. Күрәсең, икесенең тормышы да бал-майдан гына булмаган. Колакка чалына иде инде анысы. Ярар, һәркем үз гамәле өчен үзе җавап бирә... Ильяс үлгәч, күмәргә дә килмәде Нина, йөрәк урынына нәрсә булгандыр аның. Малае килде, булышкалап йөрде. Минем малайлар кайгыртты күмү мәшәкатьләрен. Олы улымның телефоны шалтыраган иде, эшеннән булды микән... Трубкасын алды да: “Монда бер кеше үлгән иде, шуны күмүдә әле мин”, – диде улым. “Әтине җирлибез”, димәде, бер кеше диде...

**Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА.**

## Колак салсаң, үкенмәссең

** Ата-ананы тыңлаган — адәм булган, тыңламаган — әрәм булган*

** Анаң өчен уч төбендә тәбә куырсаң да бурычыңны кайтара алмассың*

** Башсыз өйдә ата торып ул сөйләр,*
*Ана торып кыз сөйләр.*

** Чыбык чакта бөгелмәгән, таяк булгач бөгелмәс*

** Ата-ана теләге*
*Утка-суга батырмас.*

** Бу дөньяда өч нәрсә эзләп табылмас: бере ата, бере ана, бере карендәш*

** Ымны белмәгән нине белсен?*
*Атасын белмәгән кемне белсен?*

** Аттан тай узар,*
*Атадан бала узар*

** Ана баланы ике кат тудыра:*
*Бер кат — тән биреп!*
*Икенче кат — тел биреп!*

# Мактанма!

Аллаһ Раббыбыз кешегә төрле сәләт, төрле байлык, төрле дәрәҗә биргән. Әлбәттә, бу синең булдыклылыгың түгел, бу - Аллаһның сине сынавы. Нәрсәгә ирешсәк тә, нинди генә биеклекләргә күтәрелсәк тә, «мин булдырам бит», дип мактанырга тиеш түгелбез. Мактану гадәткә кереп китә күрмәсен. Белеп торыйк, мактану ул кешеләр алдында дәрәҗәңне төшерә, башкаларның һәм Аллаһның ачуын чыгара. Берәр кешенең мактанып утыруы, хәтта якын дустыбызның да шулай сөйләве безгә ошыймы? Юк бит, ачуны чыгара, саруны кайната, кайвакыт косасы килә башлый. Белеп торыйк: безнең мактануыбыз да башкаларда шундый ук хис уята. Мактанчык кеше яныбыздан китү белән, аны гаепләргә ашыгабыз.

Истә тотыйк: әгәр мактансак, безне дә шул ук хәл көтә. Диңгез иң түбәндә булса да, барча сулар аңа омтыла. Әгәр без дә үзебезне түбәнчелекле итеп тота алсак, башкалар да безгә таба омтылыр. Дингә чакыруны да үзеңне түбәнчелекле итеп тотудан башлау кирәк. Байлык та, дәрәҗә дә вакытлы, Аллаһ ризалыгы өчен кылган гамәлләребез генә мәңгелек һәм Кыямәт көнендә дә кыйммәтен югалтачак түгел. Шуңа күрә ниндидер уңышка, дәрәҗәгә ирешкәнбез икән, мактанганчы: «Йа Раббым, мине шөкер кылучылардан кыл һәм бу имтиханны Үзеңә муафыйк гамәлләр белән үтеп чыгуны насыйп кыл», - дип дога кылыйк.

**Җәлил хәзрәт ФАЗЛЫЕВ,**
**Татарстанның баш казые.**

# КӨЗГЕ

Пәйгамбәребез (с.г.в.): "Бер иманлы бәндә икенче иманлы бәндәнең көзгесе", - дип әйткән. Әлеге хәдистә пәйгамбәребезнең көзге белән мисал китерүе тирән мәгънәгә ия. Әйе, көзгенең вазыйфасы - ачыклау, бер әйберне күрсәтү, үзендә чагылдыру. Асылда көзге кешенең матур якларын күрсәтү белән бергә кимчелекләрен дә күрсәтә. Һәм көзгенең кимчелекләребезне күрсәтүе матур якларыбызны күрсәтүгә караганда күпкә яхшырак һәм файдалырак. Чөнки кимчелекне күргән вакытта гына аңардан котылып һәм арынып була. Шуңа күрә, иманлы кешеләр чын мәгънәсендә бер-берләренә көзге кебек булырга тиешләр. Әмма әлеге сүзне дә дөрес аңларга кирәк. Бер-береңнең кимчелеген күреп, ул кимчелекне бөтен дөньяга таратып йөрү, күргән кимчелекне кешенең битенә бәреп әйтү, аны кешеләр каршысында әйтеп, кимчелеккә ия булган кешене мәсхәрә итү, түбәнсетү матур күренеш түгел. Дөреслектә шәригать кешенең кимчелеген йөзенә бәреп аны кимсетүне тыйган. Пәйгамбәребезнең оныклары Хәсән белән Хөсәен бер карт кешенең дөрес итеп тәһарәт алмавын күргәч, әлеге олы кеше янына килеп: "Абзый, без тәһарәтне дөрес алабызмы икән? Без тәһарәт алыйк. Ә син исә карап тор. Без ялгышсак, дөреслә", - дип әйтәләр. Әлеге кеше аларның тәһарәт алуын карап торып: "Сез дөрес аласыз. Ялгышлык миндә икән", - дип, үзенең хатасын дөресләгән. Менә шушы мисалда кешене кимсетмичә дөресләү чын мәгънәсендә бер-береңә көзге булу мәгънәсен үз эченә ала.

**Мәхмүт хәзрәт ШӘРӘФЕТДИН.**

# Чапан

*(Хуҗа Насреддиннең хикмәтле мәзәкләре)*

Бер көнне иртән Хуҗа Насреддиннең хатыны ишегалдына чыккан жиреннән өйгә сөмсере коелып керә. Кәефе төшкәнен күреп, Хуҗа иплән кенә: "Ни булды?" – дип сорый.

- Кичтән чапаныңны юып ишегалдында элгән идем, бүген иртән чыксам – чапаныңнан җилләр искән... Урлаганнар...

Бу хәбәрне ишетүгә, Хуҗа, йөзендә шатлык балкытып:

- И-и, Аллага шөкер! – дип әйтеп куя.

Хатынының: "Нәрсәгә шатланасың, тинтәк?" – дигән ачулы соравына Хуҗа Насреддин болай ди:

- Ничек инде шатланмаска? Ярый әле чапан эчендә мин булмаганмын, юкса чапаны белән бергә мине дә урлап китәрләр иде!

***Кыскача нәсыйхәт: Ни генә булса да, күңелне төшермичә, "моннан да начаррак булырга мөмкин иде", дип уйлап, проблемаларга ирония аша карарга тырышыйк. Дөрестән дә, шулай иту тормышны җиңеләйтә.***

**Ришат хәзрәт Курамшин әзерләде.**

*Балалар өчен*

## Дөньяларым яктыра

Кол Шәриф дигән мәчет бар
Башкалабыз Казанда.
Көн саен азан тавышы
Яңгырап тора анда.

Намаз укыйлар мәчеттә
Мөселманнар бергәләп.
Мин дә кайчак бабам белән
Йөрим анда кергәләп.

Вәгазь тыңлыйм, намаз укыйм,
Дөньяларым яктыра.
Әйтерсең Кол Шәриф үзе
Мине чакырып тора.

**Мөҗәһит ӘХМӘТҖАНОВ**



## Саулыгым – байлыгым

# Кызыл чөгендер

Кызыл чөгендер иң беренче чиратта азканлылыктан бик файдалы. Бертигез күләмдәге чөгендер, кишер һәм әче торма сутлары кушылмасы белән электән үк азканлылыкны дәвалаганнар. Шундый кушылманы берничә ай дәвамында көн саен, ашар алдыннан, 1-2 шәр аш кашыгы эчәргә кушалар. Хроник эч кату вакытында ач карынга 100-150 г пешкән чөгендер ашарга киңәш ителә. Чөгендердә йод күп, шунлыктан ул атеросклероз, тиреотоксикоз белән интегүчеләргә файдалы. Чи чөгендер сутын матдәләр алмашын яхшыртучы һәм организмны ныгытучы чара буларак эчәргә була. Пешкән чөгендер гипертония авыруларыннан булыша, чөнки анда кан басымын төшерергә ярдәм итүче магний шактый күп. Кан басымы югары булганда һәм тынычландыручы чара буларак, яртылаш бал белән кушылган чөгендер суты эчәләр (көнгә 3-4 тапкыр яртышар стакан). Томау төшкәндә, пешкән чөгендер суты белән борын эчен юалар. Ангина вакытында чөгендер согы белән тамакны чайкарга мөмкин. Косметологлар бит тиресен яшь саклау өчен чи чөгендер согы кулланырга киңәш итә. Бу яшелчә организмны, канны, бөер һәм бавырны токсиннардан һәм агудан тиз чистарта. Бөердә таш булган, яки башка кимчелек булган очракта, эч киткәндә, ашказаны авыртканда чөгендер кулланырга киңәш ителми.



*(Фотолар интернеттан алынды)*

## Тәмле булсын!

# Балан бәлеше



Камыр өчен: 250 гр кибет каймагы (нинди майлылыкта да ярый), 1 йомырка, 4 аш калагы көнбагыш мае, тоз, әз генә шикәр комы, он, 1 чәй калагы көпшәкләндергеч. Эш тәртибе: камыр басабыз, бик йомшак булмасын; ким дигәндә ярты сәгатькә суыткычка куеп торырга. Эчлек өчен: баланны кайнаган суда пешереп алырга, сөзәргә, суытырга, шикәр комы, крахмал (яки манный ярмасы, он) салып болгатырга, бер генә алма булса да турап салырга. Табага камырны җәйгәч, камыр өстенә әз генә крахмал сибәргә. Йомшак булсын өчен, пешкән бәлешне фольгага төреп куярга.

**(Мәрьям Миңнегулова рецепты)**

**Нәшире**
**Иршат Гыйльметдин улы ШӘЙХАТТАР**

**Баш мөхәррир**
**Муллагалиева А. Г.**

**Тел.:** (8552) 70-51-09
**Факс:** (8552) 70-51-45

* * *

**Оештыручылары:**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, "Ислам нуры" дини эшмәкәрлек Үзәге

Газета мәкаләләрен күчереп басканда аларның "Ислам нуры"ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән хатларда авторларның стиле саклана.

**Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.**

**Электрон хатлар өчен:**
islamgazeta@mail.ru

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучы сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җавап бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

"Роспечать" агентлыгы каталогына кертелгән, язылу ел әйләнәсендә Россия Федерациясе буенча алып барыла.

Айга ике мәртәбә чыга.

**Тиражы: 1500**
**Индексы 54149**

* * *

Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга, тапшырсагыз иде. "Ислам нуры"ның һәр саны кулдан-кулга күчеп динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетаны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән "Ислам нуры" басмаханәсендә басылды.

**Нәшир, типография һәм редакция адресы:**
**423802, Яр Чаллы, Үзәк урамы, 72**

**Басарга кул куелды:**
**график буенча**
**24 октябрь 16 сәг.**
**фактта 24 октябрь 16 сәг.**
**Бәясе ирекле**